| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>БУРУНДУКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БОРЫНДЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 октябрь, 2020 ел Борындык авылы №1

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Борындык авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2020 елның 16 ноябренә 14 сәг 30 минутка Борындык авылы, Октябрь урамы, 24 нче йорт адресы буенча урнашкан мәктәп зданиесендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык торак пунктында ***үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** билгеләргә.
2. 2020 елның 17 ноябренә 10 сәг 00 минутка Борындык авылы, Борындык бүлеге, ООО“Дубрава-Агро”терлекчелек фермасы зданиесендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык торак пунктында ***үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының икенче этабын*** билгеләргә.
3. 2020 елның 17 ноябренә 14 сәг 00 минутка Борындык авылы, Совет урамы, 12 нче йорт адресы буенча урнашкан Борындык авыл җирлеге советы зданиесендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык торак пунктында ***үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының өченче этабын*** билгеләргә.
4. 2020 елның 18 ноябренә 12 сәг 00 минутка Борындык авылы, Октябрь урамы, 22 нче йорт адресы буенча урнашкан клуб зданиесендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык торак пунктында ***үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын*** билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны урыны буенча Борындык авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

а) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:

- Борындык авылындагы буаны ремонтлау, чистарту һәм төзекләндерү, моның өчен материаллар сатып алу;

- урамнардагы яктырткычларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

- авыл җирлегендә торак пунктлардагы чүплекләр территорияләрен чистарту;

б) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар, җиһазлар сатып алу;

- су башнясын лицензияләү буенча түләү( су белән тәэмин итү чыганагының артскважинасын куллану өчен санитар-эпидемиологик бәяләмәне документаль рәсмиләштерү, су анализы һәм башка документлар);

в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;

- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

г) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны беренчел янгын куркынычсызлыгы чарасы белән тәэмин итүне оештыру:

- янгын сүндерү машинасын ремонтлау һәм техник запчастьләр сатып алу.

д) җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру:

- сатып алынган материаллар белән зират коймасын тоту.

« РИЗА» «КАРШЫ»

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Борындык авыл җирлеге Башлыгы А. Р. Гайнетдинов